ШИМБӘ
13
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 36 (6758)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

Безнең гаскәрләр Краснодар, Шахты, Красноармейское, Ворошиловск шәһәрләрен алдылар

1. 12 нче февральдә Кубаньда Советлар Союзы Герое генерал-майор иптәш И. П. РОСЛЫЙ һәм генерал-майор иптәш А. И. РЫЖОВ гаскәрләре, кискен атака нәтиҗәсендә, КРАСНОДАР шәһәрен алдылар. Краснодарга беренче булып генерал-майор иптәш Н. Ф. ЦЕПЛЯЕВ, полковник иптәш П. К. БОГДАНОВИЧ һәм подполковник иптәш М. М. ИВАНОВСКИЙ частьлары бәреп керде. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде.

2. Генерал-лейтенант иптәш В. Д. ЦВЕТАЕВ гаскәрләре, һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, ШАХТЫ шәһәрен алдылар. Шәһәргә беренче булып генерал-майор иптәш М. С. КНЯЗЕВ һәм полковник иптәш И. Я. ФУРСИН частьлары керде.

3. Украинада генерал-лейтенант иптәш М. М. ПОПОВ гаскәрләре, омтылышлы һөҗүм нәтиҗәсендә, КРАСНОАРМЕЙСКОЕ шәһәрен һәм зур тимер юл узелын алдылар һәм шуның белән дошманның бик әһәмиятле тимер юл коммуникациясен кистеләр. Красноармейскоега беренче булып генерал-майор иптәш П. П. ПОЛУБОЯРОВ частьлары бәреп керде.

Шулай ук Украинада безнең гаскәрләр ВОРОШИЛОВСК шәһәрен алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

ДӘҮЛӘТ ОБОРОНА КОМИТЕТЫ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИПТӘШ И. В. СТАЛИНГА

Совет халкының юлбашчысы һәм Верховный Баш Командующий буларак Сезнең үз җитәкчелегегездә героик Кызыл Армиябезнең җиңүле рәвештә һөҗүм итеп алга баруы белән, Кызыл Армиянең бөтен совет халкының көчле һәм һәрвакыт артып бара торган булышлыгына таянуы белән рухланган хәлдә һәм Советлар Союзының, Бөек Британиянең һәм Кушма Штатларның коралды көчләренең берләшкән хәрби хәрәкәтләре белән явыз дошманны җиңү сәгатен якынайтырга омтылган хәлдә,—Чит Ил Эшләре Халык Комиссариатының һәм Тышкы Сәүдә Халык Комиссариатының СССР дагы һәм чит илләрдәге работниклары **«Ватан өчен, Сталин өчен!»** исемле танклар колоннасы төзелешенә үзләренең саклык акчаларыннан совет валютасы белән 4.555.690 сум һәм сумнарга күчерелгән чит ил валютасы белән 915.715 сум акча һәм шуның өстенә 670.305 сумлык дәүләт заемнары облигацияләре җыйдылар. Средстволар җыю дәвам итә.

Чит Ил Эшләре Халык Комиссариаты һәм Тышкы Сәүдә Халык Комиссариаты работниклары партия һәм хөкүмәт тарафыннан үз өсләренә йөкләнгән бурычларны намус белән үтәячәкләренә һәм шулай итеп Кызыл Армиягә аның изге азатлык максатын—немец оккупантларны тар-мар итү һәм аларны ватаныбыз чикләреннән куу максатын үтәүдә ярдәм итәчәкләренә Сезне, иптәш Сталин, ышандыралар.

СССР ның Чит Ил Эшләре Халык Комиссары
В. МОЛОТОВ.
СССР ның Чит Ил Эшләре Халык Комиссариатының партком секретаре КОШЕЛЕВА.
СССР ның Чит Ил Эшләре Халык Комиссариатының местком председателе КУДРЯВЦЕВ.

СССР ның Тышкы Сәүдә Халык Комиссары
А. МИКОЯН.
СССР ның Тышкы Сәүдә Халык Комиссариатының партком секретаре СИНОГЕЙКИН.
СССР ның Тышкы Сәүдә Халык Комиссариатының местком председателе КУТЯВИНА.

СССР ның Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш МОЛОТОВКА

СССР ның Чит Ил Эшләре Халык Комиссариатының партком секретаре иптәш КОШЕЛЕВАГА

СССР ның Чит Ил Эшләре Халык Комиссариатының местком председателе иптәш КУДРЯВЦЕВКА

СССР ның Тышкы Сәүдә Халык Комиссары иптәш МИКОЯНГА

СССР ның Тышкы Сәүдә Халык Комиссариатының партком секретаре иптәш СИНОГЕЙКИНГА

СССР ның Тышкы Сәүдә Халык Комиссариатының местком председателе иптәш КУТЯВИНАГА

Чит Ил Эшләре Халык Комиссариатының һәм Тышкы Сәүдә Халык Комиссариатының «Ватан өчен, Сталин өчен!» исемле танклар колоннасы төзелешенә СССР да һәм чит илләрдә совет валютасы белән 4.555.690 сум һәм сумнарга күчерелгән чит ил валютасы белән 915.715 сум акча һәм 670.305 сумлык дәүләт заемнары облигацияләре җыйган работникларына минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшыруыгызны үтенәм.

И. СТАЛИН.

ЭКОНОМИЯ ӨЧЕН КӨРӘШНЕ БЕР ГЕНӘ МИНУТКА ДА ЙОМШАРТМАСКА

Социалистик ярышта производство новаторлары—стахановчылар, рационализаторлар һәм уйлап табучылар зур роль уйныйлар. Алар производствоның эчке резервларын хәрәкәткә китереп, технологик процессларны үзгәртеп, хезмәт җитештерүчәнлеген торган саен күтәрә, эшләп чыгарылган продукциянең сыйфатын яхшырта, аның үзенә төшү бәясен киметә баралар. Шуның нәтиҗәсендә эш көченә һәм вакытка, электр энергиясенә һәм ягулыкка, материалларга экономия ясала, фронтка һәм илгә йөз меңнәрчә, миллионнарча сумлык өстәмә продукция бирелә.

Һәркайда һәм һәрнәрсәдә экономия—сугыш вакыты законы. Экономия мәсьәләсе социалистик ярыш договорларында һәм йөкләмәләрендә төп пунктларның берсе булып торырга тиеш. Бу пунктны чын мәгънәсе белән тормышка ашырмый торып, ярышта җиңеп чыгарга мөмкин түгел. Моның шулай икәнен бик күп фактлардан күрергә була.

Шушы көннәрдә ВКП(б) ның шәһәр комитеты һәм хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр советы башкарма комитеты шәһәр предприятиеләренең 1942 нче елның IV нче кварталында ягулыкка, җылылык һәм электр энергиясенә экономия буенча социалистик ярышларына йомгак ясады. Ярыш барышында шәһәрдә 5.300.000 киловатт-сәгать электр энергиясенә һәм 4.500 тоннага якын ягулыкка экономия ясалган. Алдынгы сафта—баш инженерлары Корнеев, Касаткин һәм Зафьянцев иптәшләр булган Н-че заводлар,. Мехкомбинат һәм «Спартак» комбинаты. Җиңүче коллективларга байрак һәм грамоталар тапшырылачак.

Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл Байрагын алуга лаеклы булган Н-че завод (партоешма секретаре урынбасары иптәш Ставер) экономия өлкәсендә дә җитди уңышларга иреште. Рационаллаштыру тәкъдимнәрен тормышка ашыру нәтиҗәсендә январь аенда миллион сумлык экономия алынды. Продукциянең үзенә төшү бәясе 3 процентка, электр энергия расходы 2 процентка кимételде.

Ягулыкка, электр һәм җылылык энергиясенә экономия өчен ярыш шәһәрнең күп кенә предприятиеләрендә яхшы нәтиҗә бирде. Ләкин ярыш барлык предприятиеләрдә дә киң җәелдерелде һәм яхшы нәтиҗә бирде дип әйтеп булмый әле. Кайбер урыннарда ул бик сүлпән алып барылды, нәтиҗәләр дә мактарлык булмады. Мәсәлән, завком председателе урынбасары иптәш Горовская булган Н-че заводта электр энергиясенә, ягулыкка, парга, суга ныклы экономия урынына, аларны әрәм-шәрәм итү фактлары күп булды. Заводның кайбер цехларында пар проводлары, коммуникацияләр әле дә төзек түгел. Вентильләрдән пар чыгып тора, изоляцияләр купкан. Шуның аркасында анда дистәләрчә тонна пар әрәмгә китә.

Шәһәр предприятиеләрендә мондый фактларның булуын бары тик партия-хуҗалык работникларының гамьсезлекләре, әшкә салкын караулары белән генә аңлатырга мөмкин. Экономия режимы—сугыш вакыты законы ул. Бу законны бозуларга каршы ныклы көрәш алып барырга кирәк. Һәрбер киловатт - сәгать электр энергиясен, һәрбер килограмм ягулыкны артык тотуның җинаять икәнен аңларга вакыт инде.

ВКП(б) ның Казан шәһәр комитеты, 1943 нче елның 1 нче январена тотылган күләм белән чагыштырганда, ягулыкка, җылылык һәм электр энергиясенә 1943 нче елның 1 нче маена кадәр 10 процент экономия ясау бурычын куйды. Моның өчен предприятиеләрдә җылылык хуҗалыгының эксплоатациясенә игътибарны көчәйтергә, җылылык энергиясенең эшләнешен һәм тотылуын учетка алуны юлга салырга, суга һәм парга контроль үлчәү приборлары куярга һәм башка төрле оештыру-техник чаралар үткәрергә кирәк.

Экономия өчен ярыш дәвам итә. Беренче уңышларны ныгытырга һәм арттырырга кирәк. Ярышка шәһәрдәге барлык предприятиеләр һәм электр станцияләр кушылырга тиеш.

Совет информбюросыннан

12 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

12 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Дон районында безнең гаскәрләр һөҗүм операцияләре алып бардылар. Бер участокта Н-че укчы часть сугышчылары, көчле артиллерия ярдәме белән, немецларны көчле итеп ныгытылган позицияләрдән бәреп чыгардылар. Дошманның ДЗОТ лары һәм блиндажлары җимертелде. 3 танк, 8 орудие, 15 пулемет һәм бер сугыш припаслары складында кулга төшерелде. Ново-Черкасскидан төньяк-көнчыгыштарак безнең частьлар халык яши торган күп кенә зур пунктларны алдылар. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Краматорская районында безнең гаскәрләр дошман танкларының һәм пехотасының контратакаларын кире кайтардылар. Бер участокта булган бик каты сугышта немецларның моторлаштырылган пехотасының танклар белән көчәйтелгән бер отрядын тар-мар иткелде. Сугыш кырында дошманның 400 гә якын үле гәүдәләре, яндырылган 9 танкысы, 2 бронемашинасы һәм 11 автомашинасы калды.

* * *

Чугуев — Лозовая районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм дошманның бик әһәмиятле юлларын кистеләр. Совет гаскәрләренең алга баруына тоткарлык ясарга маташып, немецлар сугышка эсэс частьлары керттеләр. Безнең сугышчылар, омтылышлы ударлар ясап, дошманны гаять зур югалтуларга дучар иттеләр һәм дошман ашыгыч рәвештә чигенде. «Рейс» дивизиясенең «Дейчланд» исемле эсэс полкыннан плен алынган солдатларның әйтүенчә, соңгы вакытларга кадәр алар Франциядә булганнар. 14 нче январьда аларны вагоннарга төяп, ашыгыч кына Харьковка җибәргәннәр. Беренче сугышта ук полкның роталары һәрберсе 60—70 кешеләрен югалтканнар. Дивизиядә булган 60 танктан бары 25 танк калган.

Бер участокта безнең кавалеристлар ике рота гитлерчыларны кырдылар һәм 5 орудие, 28 автомашина, күп пулеметлар, автоматлар һәм винтовкалар кулга төшерделәр. Н-че танк подразделениесе немецларның 7 танкысын һәм 18 орудиесен юк итте. Пленныйлар алынды.

* * *

Курскидан көньяктарак безнең частьлар алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че частьның разведка отряды төнлә белән дошман тылына барып чыкты һәм немецларның халык яши торган бер пункттагы батальонын тар-мар итте. Разведчиклар дошманның бер артиллерия складын шартлаттылар һәм төрле сугыш йөкләре төялгән 18 автомашинасын яндырдылар.

* * *

Орел өлкәсенең бер районында хәрәкәт

(Ахыры 4 нче биттә).

Рәсемдә: партком секретаре урынбасары иптәш М. Хәсәнов булган Н-че завод стахановчылары О. А. Затеева һәм А. Н. Шулятьева иптәшләр. Алар норманы 250—300 процент үтиләр. С. Парфенов фотосы.

Язгы чәчүгә әзерлектә комсомолның активлыгын кәчәйтергә

Ватан сугышы шартларында комсомол оешмаларына гаять җаваплы бурычлар йөкләнә. Алар яшьләрне партиябезнең, хөкүмәтебезнең карарларын үтәүгә, героик Кызыл Армиябезгә барлык көч белән ярдәм итүгә тупларга тиешләр.

Комсомол оешмаларының күпчелеге бу бурычны намус белән үтиләр. Мәсәлән, «Кустарь» колхозы янындагы комсомол оешмасын (секретаре иптәш Шәйхиева) һәм «Әсәнбаш» колхозы янындагы комсомол оешмасын (секретаре иптәш Хисамова) алыйк. Бу оешмаларның членнары яшьләр арасында политик-масса эшләрен киң җәелдерделәр һәм үзләре колхоз производствосының барлык тармакларында алдынгылык ролен уйныйлар. Бу колхозларда игеннәрне урып-җыю, дәүләткә ашлык һәм башка продуктлар тапшыру срогыннан алда үтәлде.

Комсомолецлар колхозда һәрбер политик чараларны үткәрүдә оештыручылар, инициаторлар булып торалар. «Кустарь» колхозында танклар колоннасы төзүгә 100 мең сум акча җыеп тапшырылды. Кызыл Армиягә бүләк итеп 420 пот ашлык җыеп озатылды.

«Әсәнбаш» колхозы комсомолецлары да язгы чәчүгә әзерлектә стахановча хезмәтнең гүзәл үрнәкләрен күрсәтteләр. Алар үрнәгендә барлык колхозчылар ярышып эшләделәр. Биредә язгы чәчүгә әзерлек эшләре тулысы белән төгәлләнде инде. Комсомолка иптәш Хисамова җитәкчелегендәге яшьләр бригадасы запас частьлар җыйнап, машиналарга ремонт эшен вакытыннан алда төгәлләде. Орлыклар тулысынча чистартып салынды. Яшьләр һәр көн саен орлыкларның ничек саклануын тикшереп торалар.

Ләкин, райондагы кайбер комсомол оешмалары һич тә канәгатьләнерлек эшләмиләр әле. «Революция» колхозы янындагы комсомол оешмасының эше аеруча характерлы булып тора. Бу оешманың секретаре иптәш Әхмәтҗанова җаваплылык сызлык күрсәтә. Үзенең эшен ватан сугышы таләпләренә каратып оештырмый. «Күргәзмә» колхозы янындагы комсомол оешмасы (секретаре иптәш Вәлиева) да яшьләр арасында политик-тәрбия эшләре алып бармый, колхоз производствосында яшьләрнең алдынгылык өчен көрәшен оештырмый. Бу колхозда ашлык сугу, дәүләт йөкләмәләрен үтәү әле дә төгәлләнмәгән. Язгы чәчүгә әзерлек эшләре дә бик начар тора.

Шулай ук биредә алдынгы яшьләрне комсомол сафларына тарту буенча да бер эш тә алып барылмый. Ватан сугышы башланганнан бирле комсомол сафларына бер генә кешенең дә кабул ителмәве моңа ачык мисал булып тора.

Партоешма булмаган урыннарда комсомол оешмаларының роле тагын да зур. Шуңа күрә мондый оешмаларга ВЛКСМ ның район комитеты аеруча игътибар бирергә, аларның эшенә практик ярдәм итәргә тиеш иде. Кызганычка каршы, Кукмара районында без моны күрә алмыйбыз.

Комсомол оешмаларының бурычы язгы чәчүгә отлично әзерлекне тәэмин итүдән, чәчүне вакытында үткәреп 1943 нче елда мул иген уңышы алу өчен көрәшне җәелдерүдән гыйбарәт. Тирес чыгаруны, көл, кош тизәге җыйнау, кар тотуны, авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт өчен запас частьлар җыюны, агротехника укуларын оештырырга кирәк. Бу конкрет бурычларны үтәү буенча комсомолецлардан, яшьләрдән аерым бригадалар төзәргә, бу эшкә пионерларны, мәктәп балаларын тартырга кирәк.

Шулай ук комсомол оешмалары язгы чәчүгә карата масса-аңлату эшләрен, социалистик ярышны киң җәелдерергә, бу эштә клуб, уку өе һәм кызыл почмаклардан тулы файдаланырга тиешләр.

Ш. ФӘТТАХОВ,
Кукмара МТС ы политбүлек начальнигы ярдәмчесе.

Кызыл Армиянең 25 еллыгын яңа җиңүләр белән каршылыйк!

ҖИРЛЕ ПРОМЫШЛЕННОСТЬНЫҢ УҢЫШЛАРЫ

Татарстанның җирле промышленность предприятиеләре январь аенда планнарны арттырып үтәделәр. Наркомат күләмендә айлык план валовой продукция буенча—106,4 процентка, киң куллану товарлары эшләп чыгару буенча—141,5 процентка үтәлде.

Күпчелек предприятиеләр һәм райпромкомбинатлар планнарны үтәүдә һәм арттырып үтәүдә зур тырышлык күрсәттеләр. Чистайдагы галантерея фабрикасы, мәсәлән, айлык планны 167,8 процентка үтәүгә иреште. Казан шәһәр промкомбинаты, чистайлылар белән ярышка актив рәвештә кушылып, январь аенда бик яхшы эшләде: валовой продукция буенча айлык план 136,2 процентка, ә киң куллану товарлары буенча—163,4 процентка үтәлде.

Арча, Чаллы, Алабуга, Красный бор, Тәкәнеш һ. б. райпромкомбинатлары үзләренең айлык планнарын барлык күрсәткечләр буенча да бик күп арттырып үтәделәр. Аеруча алганда—халык өчен киң куллану товарлары эшләп чыгару буенча алар айлык планнарны 150—160 процент һәм аннан да артык итеп үтәп чыктылар. Чаллы райпромкомбинаты, мәсәлән, валовой продукция буенча—163 процентка һәм киң куллану товарлары буенча 198,6 процентка, Бауман райпромкомбинаты валовой продукция буенча—198,6 һәм киң куллану товарлары буенча—217,5 процентка үтәделәр.

Февраль аенда наркоматның, предприятиеләр һәм райпромкомбинатлар җитәкчеләренең, партия, профсоюз оешмаларының бурычлары—ирешелгән уңышларны ныгытудан, героик Кызыл Армиябезнең 25 еллыгын тагын да зуррак җиңүләр белән каршы алу өчен көрәшүдән гыйбарәт булырга тиеш.

Әле һаман да артта калып баручы кайбер райпромкомбинатлар февраль аенда үз эшләрендә кискен борылыш булдыруга ирешергә тиешләр. Бу, аерым алганда, январь ае планын үтәмәгән Актаныш, Зеленодольск, Киров һ. б. райпромкомбинатларына карата әйтелә. Алар үзләренең начар эшләүләре, җитәкчеләренең инициативасызлык, булдыксызлык күрсәтүләре нәтиҗәсендә, наркоматның гомуми уңышларын киметүгә алып баралар. Наркомат җитәкчеләре исә мондый райпромкомбинатларны үзләренең нык контрольләре астына алырга, аларны өзеклектән чыгару чараларын күрергә тиешләр.

ГАЗЕТА ВИТРИНАСЫ

Соңгы вакытта ВКП(б) ның Бауман райкомы газета витриналарын оештыру буенча шактый эшләр башкарды. Январь аенда гына да 18 урында яңа витрина оештырылды.

Бөгелмә районының колхозларында хәзер 7—8 урында газета витриналары эшли.

Һәрбер газета витринасына башлангыч партия оешмалары тарафыннан җаваплы кешеләр беркетелгән. Ул иптәшләр витринага газеталарның вакытында эленүен тикшереп торалар.

СТАХАНОВЧЫЛАРНЫҢ УҢЫШЛЫ ЭШЛӘРЕ ҖИҢҮГӘ РУХЛАНДЫРА

Безнең бөек совет халкы ватан сугышы фронтларында героик көрәш алып баручы Кызыл Армиябез белән бик нык бәйләнгән. Тыл халкына «Кем өчен эшлисең?» дигән сорау бирсәң, «фронт өчен, дошманны тизрәк тар-мар итү өчен» дигән җавапны аласың.

Күптән түгел генә миңа Балтач районы үзәгендәге «Стахановчы» артеле эшчеләре белән очрашырга туры килде. Артельнең эшчеләре мине зур күтәренкелек белән: «Рәхим итегез, кадерле сугышчыбыз», дип каршы алдылар. Алар иң элек фронт хәлләрен сораша башладылар. Мин аларга үзем катнашкан сугыш эпизодларын, якташларыбызның батырлыклары турында сөйләдем. Беседа вакытында артельнең алдынгы стахановчысы Җуаһирә Газизова:

— Сугыш фронтыннан безнең хезмәт фронтының да һичбер аермасы юк,—дип куйды. Һәм эшчеләр үзләренең хезмәтләре турында сөйләп киттеләр.

Ватан сугышында булып кайткан Галиев Хәйдәр болай диде:

— Мин фронтта немец-фашист басып алучыларга каршы тормышымны кызганмыйча көрәштем. Хәзер мин тылдагы хезмәтем белән Кызыл Армиягә ярдәм итәм. Безнең артельдә хезмәт социалистик ярыш нигезендә оештырылган. Ярышып эшләү нәтиҗәсендә безнең эшчеләр көн саен 1,5—2 норма бирәләр, артель производство программасын ай саен арттырып үтәп бара. Кызыл Армиябезнең җиңүле һөҗүме безне бик нык шатландыра. Фронттагы җиңүләргә без производство уңышлары белән җавап бирәбез.

Стахановчы Әсма Бәдретдинова планны уртача 250 процентка үтәп килә. Ләкин ул моның белән генә канәгатьләнми әле.

— Мин яшь кеше,—ди ул.—Минем яшьтәшләр фронтта каннарын, тормышларын кызганмыйча көрәшәләр. Аларга лаеклы булу өчен мин тагын да тырышыбрак эшләргә, фронт өчен продукцияне тагын да күбрәк бирергә тиешмен.

Өйрәнчек кыз Асия Әхметова минем янга ук килде дә:

— Кадерле сугышчы, минем дә синең шикелле абыйларым бар. Алар фронтта безнең бәхетле тормышыбызны саклап калу өчен көрәшәләр. Әгәр дә аларны күрсәң, сеңлегез Асия тырышып эшли, сезнең өчен киемнәр тегәргә өйрәнә, планны һәр айда 128 процентка үтәп бара, диегез,—диде.

Бу артельдә Хәсәнова, Җиһан Минһаҗова, Григорьева, Мәдинә Гарәфиева, Җуаһирә Газизова кебек яхшы эшләүче кызлар уннарча санала.

61 яшьлек Зиннәт Гыйзәтуллин планны бер айда 280 проценттан да ким үтәми.

— Минем өч улым ватан сугышында. Тукта, мин әйтәм, картлык көнемдә фашист этләрен мылтык тотып кыйный алмасам, хезмәтем белән кыйныйм әле, дим һәм «Стахановчы» артеленә эшкә керәм. Хәзер, үзем карт булсам да, йөрәгем яшь минем, эшемдәге уңышлар белән җиңү көнен якынайтуда улларыма ярдәм итәм,—ди Зиннәт бабай һәм яшьтәше Әһлиулла бабай Нигъмәтуллин белән төзелгән социалистик ярыш договорының үтәлеше турында сөйли.

Беседа тәмамлана. Эшчеләр җылы рәвештә мине озаталар. «Кадерле сугышчы, сез яңадан сугышка барачаксыз, фронттагы дусларыгызга әйтегез, без Кызыл Армиягә һәрьяктан да ярдәм итәрбез, әгәр кирәк булса кулыбызга мылтык тотып явыз дошманга каршы көрәшергә барырбыз»,—диләр алар.

Әйе, безнең тылыбыз нык. Мин фронтка баргач «Стахановчы» артеле коллективының бердәм эшләве турында сөйләрмен. Бу безнең сугышчыларны тагын да рухландырыр.

Политрук **ГАЗИЗ ХӘЙРУЛЛИН.**

Рәсемдә: «Светоч» фабрикасының (Казан) карамель цехы бригадиры иптәш З. Миронова. Ул норманы 130 процент үтәп бара.

С. Парфенов фотосы.

КЫЗЫЛ АРМИЯ КӨНЕ АЛДЫННАН

Фронтовикларга бүләкләр

ЧИСТАЙ, 11 февраль. (Телефон буенча). «Свобода» колхозы членнарының гомуми жыелышы булды. Кызыл Армиябезнең XXV еллыгы уңае белән колхозчылар фронтовикларга бүләкләр җибәрергә карар бирделәр. Алар шул җыелышта ук 14,5 центнер ашлык, 10 сарык, сөт, май, бияләй һәм күп кенә әйберләр бирделәр. Анна Медведева 3 сарык, Мария Прокофьева 2 сарык бүләк итте. Петрова, Николаева иптәшләр 13 әр пот, Паркин 10 пот, Пашина 9 пот ашлык бүләк иттеләр. Иптәш Ватякова 6 пот ашлык һәм бер сарык тапшырды.

«Уракчы» колхозы члennары Гайсин һәм Гыйльманов иптәшләр дә берәр центнер ашлык бирделәр. Бу колхоз буенча барлыгы 15 центнер ашлык җыелды.

«Кызыл ялан» колхозы членнарыннан Галиев бер центнер, Ишморатов, Фатихова һәм Маликов иптәшләр 64 әр килограмм ашлык, 75 яшьлек Мәхупҗамал әби Кадыйрова 30 литр сөт, Хафизова 15 килограмм суган бирделәр. Бу колхозда барлыгы 75 пот ашлык һәм башка күп кенә продуктлар җыелды

ЧАҢГЫЧЫЛАР ЭСТАФЕТАСЫ

Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә Татарстанда чаңгы эстафетасы үткәрелә. 21 нче февраль, көндезге 2 сәгатьтә Казанның Ирек мәйданында эстафетага финиш ясалачак.

Татарстанның барлык районнарыннан чаңгычылар Кызыл Армия сугышчыларына бүләкләр җыю турында һәм дәүләткә ашлык тапшыру планының үтәлеше турында рапортлар алып киләчәкләр.

Эстафетаның барлык маршрутларының озынлыгы—1.680 километр. Бөгелмә—Казан маршруты—330 километр, Актаныш—Казан маршруты—300 километр, Чүпрәле—Казан маршурты—285 километр. Чаңгычылар көн саен 40—50 километр араны үтәчәкләр.

Финиш көнендә шәһәрнең чаңгычылары танклардан десант төшерүне һәм чаңгылар белән сугыш хәрәкәтләре алып баруны күрсәтәчәкләр.

А. ВОИНОВ.

«ТУН-БҮРЕК» АРТЕЛЕНДӘ

Кукмарадагы «Тун-бүрек» артеле январь ае планын 137 процентка үтәп чыкты. Киң куллану товарлары җитештерү буенча план 132 процентка үтәлде. Артельнең алдынгы стахановчылары Камалетдинова норманы 400 процентка, Галиуллин 300 процентка үтәп баралар.

Г. ГАЛИЕВ.

ЯҢА ЦЕХ

Балтач районындагы, «Красный труд» артеле (председателе иптәш Шакиров) Комала авылында сөяктән тарак һәм расческалар эшләү цехы ачты. Биредә хезмәт инвалидлары эшлиләр. Күп кенә тараклар эшләнеп чыкты да инде.

ХЕЗМӘТ БАТЫРЛЫГЫНДА ФРОНТ ГЕРОЙЛАРЫННАН КАЛЫШМАСКА!

ТРАКТОРЧЫ ХАТЫН-КЫЗЛАР, БӨТЕНСОЮЗ СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШЫНА ЧЫГЫГЫЗ!

Советлар Союзындагы барлык тракторчы хатын-кызларга Дарья Гармаш җитәкчелегендәге тракторчы хатын - кызлар бригадасының хаты

Кадерле дуслар!

Бу шатлыклы көннәрдә безнең, совет хатын-кызларының йөрәкләре Кызыл Армиянең героик сугышчылары өчен горурлык белән тулган. Киң фронт буйлап дошманга каршы җимергеч һөҗүм бара. Үч алу сәгате сукты! Кабахәт гитлерчылар безнең бәхетле совет халкын буйсындырырга уйлаганнар иде. Хәзер инде фашистлар үзләренең акылдан шашкан планнары өчен тау-тау үле гәүдәләр өемнәре белән, җимерелгән дистәләрчә дивизияләр белән түлиләр.

Немец оккупантларны тар-мар итү һәм аларны ватаныбыз чикләреннән куу өчен алга!—иптәш Сталинның шушы лозунгысы астында безнең сугышчыларыбыз дошманга каршы сугышалар. Ун меңнәрчә шәһәрләр һәм авыллар инде гитлерчы ерткычлардан азат ителде. Дошманга куәтле ударлар ясалды. Ләкин ул көчле әле. Ерткыч яраланды, ләкин әле үтерелмәгән. Фашистлар, үзләренең котылгысыз һәлак булачакларын сизеп, ярсынып каршылык күрсәтәләр. Безнең батыр сугышчыларыбыз алдында әле авыр сугышлар тора. Ләкин гитлерчы басып алучыларның арка сөякләрен сындырырбыз, без халкыбызның намусын, азатлыгын, бәйсезлеген саклап калырбыз. Без—кырларда эшләүче хатын-кызлар—туганыбыз Кызыл Армиягә ярдәмгә бөтен көчебезне, бөтен белемебезне, йөрәгебезнең бөтен җылысын бирербез.

Кадерле дуслар! Быелгы икенче сугыш язында, колхозларда һәм совхозларда тракторлар, җанлы тарту көчләре һәм эш көчләре саны кимегән шартларда, чәчүне һәм башка төрле кыр эшләрен уңышлы үткәрү, кайчан гына булганга караганда да күбрәк дәрәҗәдә, тракторлардан, комбайннардан һәм авыл хуҗалыгы машиналарыннан тулысынча һәм югары җитештерүчәнлек белән файдалануга—безнең уңышлы эшләвебезгә бәйләнгән. Шулай булгач колхозларда һәм совхозларда мул иген уңышы үстерү һәм җыеп алу өчен, Кызыл армиягә, илебезгә ашлыкны, бәрәңгене, яшелчәләрне һәм техник культураларны күбрәк бирү өчен тырышып эшлик.

Без, Рязань өлкәсе, Рыбново МТС ының тракторчы хатын-кызлары, үткән елның язында тракторчы хатын-кызлар бригадаларының Бөтенсоюз социалистик ярышына кушылган идек һәм без машинадан алырга мөмкин булганның бөтенесен алырлык итеп эшләдек.

Үткән елның беренче яртысында без тракторчы хатын-кызлар бригадалары ярышында бөтен Союз күләмендә беренчелек яулап алдык. ВЛКСМ Үзәк Комитетының Кызыл Байрагын алганнан соң без тагын да яхшырак эшләргә тырыштык.

Ел ахырында безнең бригадабызда һәрбер ХТЗ тракторы, йомшак сөрүгә күчереп исәпләгәндә, 1.077 гектар эшләде. Безнең бригада 6.082 килограмм ягулыкка экономия ясады. Бу—тракторчы хатын-кызларның фронтовикларга бүләге булды. Күптән түгел комсомолга алынган Маруся Кострикина 545 гектар сөрде һәм 1.450 килограмм ягулыкка экономия ясады. Ул 757 хезмәт көне эшләде һәм шулар өчен 2.272 килограмм ашлык алды.

Без туфракны вакытында һәм чын күңел биреп эшкәрттек. Колхозларның югары уңыш бирүләрендә безнең хезмәтебезнең дә шактый өлеше кергәнлеген аңлау күңелле. «Красный пахарь» артеле колхозчылары безнең тракторчылар сөргән участоклардан гектарыннан 17 шәр центнер ашлык җыеп алдылар.

Авыр сугыш елын без әнә шулай тәгалләдек. Ләкин безгә, совет хатын-кызларына, ирешелгән уңышлар белән тынычлану ярыймы соң? Билгеле, ярамый. Хезмәттә кыю һөҗүм белән фронтовикларның һөҗүменә булышлык итү—безнең изге бурычыбыз. Быелгы язгы чәчү бездән тагын да күбрәк уңышлар таләп итә, һәм без Советлар Союзының барлык тракторчы хатын-кызларына сугышчан чакыру белән мөрәҗәгать итәргә карар бирдек.

Кадерле хезмәттәш дусларыбыз! 1943 нче елны югары иген уңышы алу өчен тракторчы хатын-кызлар бригадаларының социалистик ярышына кушылыгыз! Машиналардан тулысынча файдалануга ирешик, һәрбер трактор белән эшләүне арттырыйк, кырларны эшкәртүне яхшыртыйк, ягулыкның һәрбер тамчысын саклыйк.

Безнең бригадабыз инде язга тулысынча әзерләнде. Барлык тракторларга һәм тагылма инвентарьга ремонт ясалды. Без үзебезнең эш участокларыбызны беләбез. Быел югары уңыш өчен көрәшне тагын да активрак оештыручылар булу өчен хәзер агротехниканы бик тырышып өйрәнәбез.

Социалистик ярышка чыгып, безнең бригадабыз үз өстенә түбәндәге йөкләмәләрне ала:

— 15 ат көчле һәрбер трактор белән, йомшак сөрүгә күчереп исәпләгәндә, кимендә 1.100 гектар сөрергә;

— чәчүне, урып-җыюны, пар җирләрен һәм туңга сөрүне иң кыска срокларда һәм югары сыйфатлы итеп үткәрергә;

— ягу һәм майлау материалларына, билгеләнгән нормаларга карата, кимендә 15 процент экономия ясарга;

— эшсез торуларга юл куймаска, тракторларны техник тәрбияләүнең барлык кагыйдәләрен график буенча нык үтәргә, машиналарның берниндидә ватылуларына юл куймаска. Без үзебезнең машиналарыбызны фронтовиклар үзләренең сугыш коралларын саклаган кебек игътибар белән саклarбыз.

Кадерле дуслар! Социалистик ярышка кушылыгыз, конкрет йөкләмәләр алыгыз һәм аларны хәзер үк, язга әзерлек барышында ук, төгәл үтәгез.

Безнең колхоз кырларындагы тырыш хезмәтебез немец-фашист басып алучыларны тәмам тар-мар итүне тизләтсен.

1943 нче елны югары иген уңышы җыеп алыйк! Немец оккупантларны тар-мар итүдә һәм җиребездән куууда Кызыл Армиягә бөтен көчебез белән ярдәм итик.

Рязань өлкәсе, Рыбново МТС ының хатын-кызлардан төзелгән 10 нчы номерлы трактор бригадасының бригадиры

ДАРЬЯ ГАРМАШ.

Бригадир ярдәмчесе

НИКОЛАЙ ФИНОГЕНОВ.

Тракторчылар: **Полина Титова, Анна Анисимова, Мария Кострикина, Анна Батурина, Анна Стародымова, Вера Устинова, Мария Матуся.**

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ОТЛИЧНО ӘЗЕРЛӘНЕРГӘ

ТРАКТОРЛАР ӘЗЕР

АКТАНЫШ, 12 февраль. (Телеграф буенча). 10 нчы февральгә Актаныш МТСы тракторларга ремонт ясауны тулысынча тәмамлады. Ремонтның сыйфаты яхшы.

ВКП(б) райкомы секретаре **ГАЗИЗОВ,**
МТС директоры **ФИЛИППОВ,**
Политбүлек начальнигының урынбасары **ХӘБИБУЛЛИНА,**
МТС механигы **МУЗЕЕВ.**

ЯХШЫ ӘЗЕРЛЕК БЕЛӘН

КУКМАРА, 11 февраль. (Телефон буенча). Данлыклы Кызыл Армиябезнең гүзәл җиңүләре белән рухланып, Разин исемендәге колхоз членнары язгы чәчүгә әзерлекнең темпын берничә тапкыр көчәйттеләр. Колхозчылар чәчүлек орлыкларны чистартуга, аларның саклынышына аеруча зур игътибар бирделәр. Район орлык лабораториясендә тикшергәч, орлыкларның тишелеп чыгышы яхшы дип табылды. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт тулысы белән тәмамланды. Ремонттан чыккан барлык машиналар комиссия тарафыннан акт белән кабул итеп алынды.

Агротехника чараларын үткәрү дә яхшы бара. Кар тоту планы (350 гектар) тулысы белән үтәлде. Басуга тирес чыгару 80 процентка үтәлде. Көл, кош тизәге һ. б. җирле ашламалар җыю да уңышлы бара. Агротехника түгәрәкләре күптән башланды. Анда 32 кеше укый. Колхозчылар түгәрәккә зур кызыксыну белән йөриләр. Түгәрәкнең занятиеләре план буенча алып барыла.

Атларның торышы яхшы. Алексеева һәм Романова иптәшләр атларны тәрбияләүдә күпләргә үрнәк булып торалар.

«Байлангыр» һәм «Әзлян» колхозларында да язгы чәчүгә әзерлек эшләре төгәлләнеп килә.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

12 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

итүче партизаннар отряды январь аенда дошманның 4 хәрби эшелонын юлдан чыгарган. 4 паровоз, 8 вагон, сугыш техникасы һәм сугыш припаслары төялгән 17 платформа җимерелгән. Орел партизаннарының икенче бер отряды халык яши торган бер пунктта немецлар гарнизонын тармар иткән. 60 гитлерчы үтерелгән, терлекләр көтүе кулга төшерелгән. Бу терлекләрне немецлар Германиягә озату өчен крестьяннардан талап алган булганнар.

* * *

Германиядән фашистлар каторгасыннан качып кайткан. В. Татаринова һәм Т. Панков болай диделәр: «1942 нче елның июнендә безне, Курск өлкәсе, Ново-Каронино авылының башка кешеләре белән берлектә, ирексезләп Германиягә алып киттеләр. Анда безне хәрби пленныйлар өчен ясалган, чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган лагерьга яптылар. Безгә хайваннарга караганнан да начаррак карадылар. Һәрбер кабахәт фашист җылан безне мыскыл итте. Безне тәүлегенә 16—18 әр сәгать эшләргә мәҗбүр иттеләр һәм ачлык белән газапладылар. Немецлар каторгасыннан котылып, үз җиребезгә кайтканнан соң үз авылыбызда Кызыл Армияне очраткач безнең нидәрәҗәдә шатланганлыгыбызны сүз белән әйтеп бетерү кыен. Хәзер без фашизм изүеннән бөтенләйгә котылдык».

* * *

Соңгы вакытларда Карпат арты Русенда партизаннарның активлыгы шактый көчәйгән. Партизаннарның бер отряды немецларның гаскәрләр һәм сугыш припаслары төялгән 3 тимер юл эшелонын һәлак итүне оештырган. Икенче бер отрядның партизаннары Германия промышленносте өчен эшчеләр «туплый» торган немец-венгер комиссиясенең членнарын тотып алганнар. Бу комиссия хезмәткә яраклы халыкны ирексезләп Германиягә куып торган булган. Партизаннар комиссиянең членнарын һәм аларны озатып баручы сакчыларны үтергәннәр.

12 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

12 нче февральдә Кубаньда безнең гаскәрләр, кискен атака нәтиҗәсендә, **Краснодар** шәһәрен, шулай ук район үзәге һәм тимер юл узелы **Тимашевскаяны**, район үзәкләре һәм тимер юл станцияләре **Роговскаяны, Динскаяны, Новотитаровскаяны** һәм район үзәге **Тохтамукайны** алдылар.

Безнең гаскәрләр, һөҗүмне җәелдерә барып, **Шахты** шәһәрен һәм район үзәге **Кривянскаяны** алдылар.

Украинада безнең гаскәрләр, омтылышлы һөҗүм нәтиҗәсендә, **Красноармейское** шәһәрен һәм зур тимер юл узелын алдылар, шуның белән дошманның бик әһәмиятле тимер юл коммуникациясен кистеләр.

Украинада безнең гаскәрләр шулай ук **Ворошиловск** шәһәрен алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

11 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 8 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 250 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 20 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 3 сугыш припаслары складын һәм бер ягулык складын шартлаттылар, бер батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Ростов-Дон районында каты каршылык күрсәтүче дошман частьларына каршы безнең гаскәрләр сугышлар алып бардылар. Бер участокта безнең сугышчылар немецлар пехотасының һәм танкларының 5 контратакасын кире кайтардылар. Сугыш нәтиҗәсендә немецларның 7 танкысы зарарланды һәм яндырылды. Икенче бер участокта гвардия лейтенанты Поршиков командалыгындагы танк дошман танклары засадасына барып чыккан иде. Безнең танкистлар немецларның 14 танкысына каршы кыюлык белән сугышка керештеләр һәм дошманның 4 танкысын сафтан чыгардылар.

* * *

Төньяк Кавказда кичә һава сугышларында һәм безнең зенит артиллериясе уты белән немецларның 31 самолеты юк ителде. Краснодар районында зенит артиллериясе уты белән немецларның 2 самолеты атып төшерелде. Аларның очучылары парашютлар белән төштеләр һәм плен алындылар. Плен алынган немец очучыларының әйтүенә караганда, алар шушы көннәрдә Тунистан Совет—Германия фронтына китерелгән, пикировать итүче бомбардировщиклар эскадрасы составында булганнар.

* * *

Краматорская районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм дошманның күп кенә терәк пунктларын, шул исәптән 2 тимер юл станциясен алдылар. Бер участокта немецларның шактый күп танклары һәм мотопехотасы безнең позицияләргә контратака ясарга маташып карадылар. Сугыш нәтиҗәсендә немецларның 13 танкысы сафтан чыгарылды. Дошманның гаять күп җанлы көчләре юк ителде һәм ул, сугыш кырында берничә орудие һәм дистәләрчә автомашиналарын калдырып чигенде.

* * *

Лозовая районында безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүм алып баруны дәвам иттерделәр. Н-че часть сугышчылары, дошманның контратакаларын кире кайтарып, алга киттеләр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Бер артиллерия батареясы, алты көпшәле 2 миномет, 13 пулемет һәм 2 радиостанция кулга төшерделәр. Икенче бер участокта немецларның бер батальон пехотасы тар-мар ителде һәм бик күп трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Белгородтан көньяктарак безнең частьлар, һөҗүмне җәелдереп, дошманны халык яши торган берничә зур пункттан бәреп чыгардылар. Бу пунктларның берсе өчен булган сугышларда 4 авыр орудие, 103 кул пулеметы һәм станоклы пулеметлар, 500 винтовка һәм башка трофейлар кулга төшерелде. 1.000 нән артык дошман солдатлары һәм офицерлары плен алынды.

* * *

Курскидан төньяктарак Н-че часть 4 көн дәвам иткән бик каты сугышларда 2.000 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырды. Бик күп трофейлар, шул исәптән 50 орудие,, 158 пулемет, 50 миномет, 850 винтовка, 150 ат һәм башка төрле күп сугыш милекләре кулга төшерелде.

* * *

Минск өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче отрядның партизаннары январь аенда дошманның 11 хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. 8 паровоз һәм 129 вагон җимерелгән. Немец оккупантларга каршы сугышларда совет патриотлары 6 орудие, 25 пулемет, 18 автомат, 296 винтовка һәм 50.000 патрон кулга төшергәннәр. Немецлардан Германиягә озату өчен әзерләнгән 2.436 баш мөгезле эре терлек һәм 2.000 тонна чамасы ашлык сугышып алынган.

* * *

Безнең гаскәрләрнең ударлары астында чигенгән чакта немецлар халык яши торган пунктларны яндыралар һәм граждан нар халкын ерткыч төстә кыралар. Орел өлкәсе, Александровка авылында гитлерчылар 27 колхозчының йортын яндырганнар. Колхозчыларның барлык милекләре янып беткән. Шул ук өлкәнең Утаковка авылында немецлар коточкыч җинаять эшләгәннәр. Фашист кабахәтләр 40 колхозчы хатын-кызны мәктәп янына җыеп китергәннәр дә, барысын бер сафка тезеп атып үтергәннәр.

ТАСС ның юкка чыгаруы

10 нчы февральдә Әнкарә радиосы түбәндәге хәбәрне таратты: «Фельдмаршал Паулюс һәм башка немец генераллары Украинадагы үзләренең җинаятьләре өчен җавапка тартылачаклар, һәм хәрби судка бирелачәкләр. Советлар болай дип саныйлар: немец генераллары совет территориясендәге хәрәкәтләре өчен үзләре җаваплы булырга тиешләр».

Әнкарә радиосының, ихтимал, Германия яклы элементлар тарафыннан таратылган бу хәбәр башыннан ахырынача уйдырма икәнлекне һәм чынлыкка һич тә туры килмәвен белдерергә ТАСС ның вәкаләте бар.

МАРСЕЛЬ КАШЕННЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

ЖЕНЕВА, 11 февраль. (ТАСС). «Радио-Франс» Франциянең мәгълүм иң карт коммунист эшлеклесе Марсель Кашенның түбәндәге белдерүен тапшырды:

«Гитлерчы оккупантларга карата Франция халкы үзенең һәрвакыт үсеп бара торган дошманлыгын көн саен күрсәтә. Басып алучылар 30 ай инде безнең халкыбызны талыйлар һәм ачлыктан үтерәләр. Йөзләрчә заложникларны ерткыч төстә җәзалап үтерүләр дәвам итә. Ун меңнәрчә французлар төрмәләргә һәм концентрация лагерьларына ябылалар. Бөтен Франция оккупацияләнде. Аның армиясе таркатылды. Аның барлык ирекләре юкка чыгарылды. Йөз меңнәрчә французлар сөрелделәр һәм каторга хезмәтләренә хөкем ителделәр. Ләкин немецлар моның белән дә канәгатьләнмиләр. Хәзер инде немецлар җиңүгә ирешү өчен Франциянең кулына корал тотып Гитлерга булышлык итүен таләп итәләр. Бу җиңүгә ирешү мөмкин түгел. Мөмкин булган хәлдә дә ул бары тик Франциянең бөтенләйгә кол ителүенә генә китерер иде. Әгәр дә Франция бу таләпне үтәмәсә, Гитлер аны җир йөзеннән себереп ташлау белән куркыта. Мондый оятсыз ультиматумга бер француз да риза булмас. Хәзер явыз дошманның изүен алып ташлау өчен һәрбер кеше үзенең көрәштәге урыным белергә тиеш. Һичшиксез, СССР ның җиңүләре һәм инглизчаннарның, американлыларның актив һөҗүмгә күчүләре Франциянең азат булуына бик нык ярдәм итәрләр. Ләкин дошманны юк итәчәк гаять зур сугышны милләтебез гади күзәтүче булып кала алмый. Франция халкы, яңадан үз җиренә хуҗа булу өчен, көрәштә катнашырга тиеш. Безнең территориябезнең бер генә почмагы да үз бурычын үтәүдән читтә калмасын. Вишидагы кешеләрнең хыянәтен аклау өчен дошман безнең бөек шагыйребезнең сүзләреннән файдалана. Безгә шагыйребезнең ялкынлы сүзләрен искә төшерергә вакыт җитте. Виктор Гюгоның тавышы безне чакыра: «Ватаныбыз өчен коточкыч сугыш ачыйк»,—ди. Азат укчылар! Куе урманнар аркылы үтегез, куәтле ташкыннар аркылы кичегез, чокырлар аша шуышып үтегез, төзәгез, атыгыз, басып алучыларны кырыгыз.

Инде миңа килсәк, минем урыным коммунистлар партиясе сафларында, көрәштәш иптәшләрем арасында. Мине берничә төрмә дә, берничә янаулар, да берничә эзәрлекләүләр дә беркайчан да коммунистлар партиясеннән йөз чөерергә мәҗбүр итә алмадылар. Коммунистлар партиясенең намусы Франциянең һәм азатлыкның дошманнарына каршы көрәшкә аның җиңүчелек итүен таләп итә. Аның көрәшчеләре фашизмга каршы беренче булып көрәш башладылар. Бүген алар Франциянең барлык патриотлары белән бергә кушылырга кайчан гына булганга караганда да күбрәк телиләр. Франция патриотлары, генерал де Голль белән берлектә, Францияне азат итү милли восстаниедән аерылгысыз дип саныйлар. Безнең никадәр иптәшләребез үтерелде! Аларның бердән-бер гонаһлары үз илләрен, үз халыкларын саклаудан гыйбарәт иде. Төрмәләрдә ничәшәр мең солдатлар газап чигәләр! Никадәр эзәрлекләнүче кешеләр, үз азатлыкларын, үз тормышларын куркыныч астына куеп, көн саен көрәш алып баралар. Мин бу көрәшчеләргә һәм бу репрессияләр корбаннарына теләктәш булып калам. Мин үземнең йөрәгемә шул кадәр якын булган, үтерелгән һәм газапланган яшь дусларымның истәлегенә турылыклы булып калам. Алар биргән корбаннар минем күз алдымда совет эшчеләре, крестьяннары, һәм интеллигенциясе, Сталин җитәкчелегендә көрәш алып баручы армия сугышчылары һәм партизаннары биргән корбаннар белән бергә кушыла. Аларның гомуми геройлыгы Европаны һәм Францияне, һичшиксез, азат итүне тәэмин итә. Мин актык сулышыма кадәр алар ягында калам».

Түбәнге палатада Черчилльнең чыгышы

ЛОНДОН, 11 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, баш министр Черчилль бүген сугыш хәле турында түбәнге палатада речь белән чыккан.

Касабланкадагы киңәшмәгә кагылып, Черчилль болай дигән:

— Бу киңәшмәдә алга куелган төп максат дошман көчләренә корыда, диңгездә һәм һавада мөмкин кадәр киң күләмнәрдә, һәм мөмкин кадәр тизрәк атака ясаудан гыйбарәт булды. Дошман Ак диңгездән алып Кара диңгезгә кадәр гаять зур Россия фронтында янган һәм канын агызган кебек, ул һәркайда да янсын һәм каны аксын өчен мөмкин булган барлык юллар белән тырышырга кирәк.

Аннары Черчилль су асты сугышының барышына тукталып үткән һәм бу яктан уңышлар барлыкны әйткән. Аннан соң Черчилль болай дигән:

— Русларның гаять зур һәм бик яхшы һөҗүмнәренә булышлык итү һәм дошманның һәм аның һава көчләрен Россия фронтыннан читләштерергә тырышу өчен Касабланка киңәшмәсендә кулдан килгәннең бөтенесен эшләргә карар бирелде, чөнки су асты сугышы мәсьәләләре безнең һөҗүм хәрәкәтләре ясавыбызга мөмкинлек бирерлек итеп куелдылар.

Соңыннан Черчилль үзенең Төркиягә барып кайтуының йомгакларына характеристика биргән. Черчилль Төньяк Африкадагы хәлгә тукталып үткән.

Речене ахырында Черчилль Атлантик океанның һәр ике ягындагы барлык патриотларга мөрәҗәгать итеп, сугыш уты кабызучыларны һәм буталчыклык тудыручыларны, алар кайда гына булсалар да, һәркайда да сытып ташларга кирәк, дигән.

Черчилль чыгышының тулы тексты Рейтер агентлыгы тарафыннан өстәмә рәвештә тапшырылачак.

КЫЗЫЛ АРМИЯ ТУРЫНДА АНГЛИЯ ОФИЦЕРЛАРЫ

ЛОНДОН, 11 февраль. (ТАСС). «Раша тудей» журналының Кызыл Армиянең алдагы 25 еллыгына багышланган махсус номерында СССР ның коралды көчләре турында Англия офицерларының күп кенә мәкаләләре урнаштырылган. Англиянең Вашингтондагы илчелеге янында авиация атташесы булып торган Чарльтон болай дип яза: «Кызыл Армиянең искиткеч уңышлары, аның оешканлыгы һәм нык торучанлыгы, гаять авыр кыенлыкларны җиңә белүе һәм, ниһаять, җиңүгә булган бердәм омтылыш көче һәм какшамаслыгы хәтта хәрби кешене дә гаҗәпкә калдыра».

Шулай ук журнал Кызыл Армия турында генерал Гофтан, парламент члены полковник Мордан һәм фельдмаршал лорд Бердвудтан алынган котлау телеграммаларын да урнаштыра.

Хәрби диңгез флоты офицеры Эдгар Юнг үзенең мәкаләсендә болай дип яза: «Кызыл Армия үзенең 25 еллыгын бәйрәм иткән чакта үзенең казанышлары аркасында яулап алган дәрәҗәсе белән мактанырга хокуклы булыр. Гитлер урдаларына каршы асылда бер үзе генә сугышкан хәлдә ул 20 ай буена дөньяда башка берничә армия дә кайтара алмаслык ударларны кире кайтарып торды».

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

БЕЛДЕРҮ

Бүген, 19 сәгатьтә ВКП(б) шәһәр комитетының Партия мәгарифе йортында, (Бауман урамы, 62 йорт) «Халыкара хәлне күзәтү» дигән темага лекция укыла. Лекцияне СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты иптәш Иванов укый.

Лекциягә керү өчен билетларны ВКП(б) райкомнарыннан һәм Партия мәгарифе йортыннан алырга.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ 643 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФ ИЯСЕ № Заказ 256